МЭР ГОРОДА
НАБЕРЕЖНЫЕ ЧЕЛНЫ
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
ЯР ЧАЛЛЫ ШӘҺӘРЕ
ХАКИМЕ

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

29 апрель 2018ел №М 170

Шәһәр Хакименең 2015 елның 27 маендагы М 166 нчы карары белән расланган кешеләр күпләп җыела торган урыннарны тикшерү буенча ведомствоара комиссия турында нигезнамәгә үзгәрешләр кертү турында

Россия Федерациясе Хөкүмәтенең «Кешеләр күпләп җыела торган урыннарның һәм Россия Федерациясе милли гвардия гаскәрләре тарафыннан мәҗбүри сакланырга тиешле объектларның (территорияләрнең) террорчылыкка каршы сакланышына карата таләпләрне һәм шундый урыннарның һәм объектларның (территорияләрнең) куркынчсызлык паспортлары формаларын раслау турында» 2015 елның 25 мартындагы 272 нче карары, шәһәр Уставының 35 маддәсе нигезендә

К А Р А Р Б И Р Ә М:

1. Шәһәр Хакименең «Кешеләр күпләп җыела торган урыннарны тикшерү буенча ведомствоара комиссия төзү турында» 2015 елның 27 маендагы М 166 нчы карары белән расланган кешеләр күпләп җыела торган урыннарны тикшерү буенча ведомствоара комиссия турында нигезнамәгә түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

1) 7 пунктны түбәндәге эчтәлектәге 5 пунктча белән тулыландырырга:

«5) Россия Федерациясе милли гвардия гаскәрләре Федераль хезмәтенең территориаль органы яки Россия Федерациясе милли гвардия гаскәрләренең ведомстводан тыш сак бүлекчәләре вәкилләре.»;

2) 9 пунктта «5 нөсхәдә» сүзләрен «6 нөсхәдә» сүзләренә алмаштырырга;

3) 10 пунктны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«10. Кешеләр күпләп җыела торган һәр урынны комиссия тарафыннан тикшерү һәм категорияләү үткәрелгәннән соң, аңа 6 нөсхәдә кешеләр күпләп җыела торган урынның уркынычсызлык паспорты төзелә, ул территориаль куркынычсызлык органы, Россия Федерациясе Эчке эшләр министрлыгының территориаль органы, Россия Федерациясе милли гвардия гаскәрләре Федераль хезмәтенең территориаль органы яки Россия Федерациясе милли гвардия гаскәрләренең ведомстводан тыш сак бүлекчәсе, Россия Федерациясе Гражданнар оборонасы эшләре, гадәттән тыш хәлләр

һәм бәла-каза нәтиҗәләрен бетерү министрлыгының территориаль органы җитәкчеләре белән килешенә һәм Яр Чаллы шәһәре Хакиме тарафыннан раслана.»;

4) 2 бүлекне түбәндәге эчтәлектәге 11 пункт белән тулыландырырга:

«11. Кешеләр күпләп җыела торган урынны категорияләү мәсьәләләре буенча комиссия әгъзалары арасында каршылыклар булганда, карар комиссия әгъзаларының күпчелек тавышы белән килештерү киңәшмәсе барышында комиссия рәисенең хәлиткеч тавышы белән кабул ителә. Җайга салынмаган каршылыклар, комиссия әгъзаларының аерым фикерләрен күрсәтеп, кешеләр күпләп җыела торган урыннарны тикшерү һәм категорияләү актына кертелә.».

2. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны Башкарма комитет Җитәкчесе Р.Ә. Абдуллинга йөкләргә.

Шәһәр Хакиме
вазыйфаларын башкаручы

Ф.И. Андреева